Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Габдрахман авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

20 октябрь 2022 ел

№14

Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авылы башкарма комитетының 2020 елның 14 нче маендагы 3 нче номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында»гыкарарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә

Габдрахман авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авылы башкарма комитетының 2020 елның 14 нче маендагы 3 нче номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авылы башкарма комитетының 2022 елның 25 нче июлендәге 11 нче номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

1 бүлекнең 4 пунктында, 2 бүлекнең 5 һәм 8 пунктларында, 3 бүлекнең 10 пунктында һәм 12 пунктның дүртенче абзацында «(яки башка вәкаләтле орган)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 бүлекнең 15.1., 16.1. пунктларын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Габдрахман авылы, Совет урамы, 77 нче йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында "(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәре Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырым.

Габдрахман авылы башкарма
комитеты җитәкчесе

Р.Ш. Мотаһиров